# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШУГАН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XII УТЫРЫШЫ

**К А Р А Р № 21**

Шуган ав. 25 май 2021 ел

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегенең норматив хокукый актларын «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2013 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 31 июлендәге 268-ФЗ номерлы Федераль законга, «Мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында»гы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан, Шуган авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 27 декабрендәге 1 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4) 4 бүлекнең 1 кисәгендәге 3 пунктның 4 пунктчасын түбәндәгечә бирергә:

«4) хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, хезмәт кенәгәсе һәм (яки) хезмәт эшчәнлеге турындагы законнарда билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерелгән белешмәләр;»;

5) 8 бүлекнең 1 кисәгендәге 1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәгечә бирергә:

«4) муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт кенәгәләрен алып бару (булган очракта), муниципаль хезмәткәрләрнең муниципаль хезмәтне узу чорында хезмәт эшчәнлеге турында белешмәләр формалаштыру һәм күрсәтелгән белешмәләрне мәҗбүри пенсия иминияте системасында индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе Пенсия фондының мәгълүмат ресурсларында саклау өчен тапшыру;»;

3) 4 бүлекнең 1 кисәгендәге 3 пунктның 6 пунктчасын түбәндәгечә бирергә:

«6) хезмәт килешүе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш, индивидуаль (персонификацияләнгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслаучы документ;».

2. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлегендә Муниципаль хезмәт турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2014 елның 29 май 1 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Шуган авыл җирлеге Советы карарын үз көчен югалткан дип санарга.

3. Әлеге карарны Шуган авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**Шуган авыл җирлеге башлыгы** **Басорина А.Ю.**